| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ<br>«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»<br>ЧИСТОПОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ** | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>**ЧИСТАЙ<br>ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ** |
|---|---|---|

***Решение*** ***Карар***

**24.05.2023 ел** **Чистай шәһәре** **№22/6**

«Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәр Советы депутаты
статусы турындагы Нигезләмәне раслау хакында»
2022 елның 02 сентябрендәге
16/5 номерлы Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2023 елның 06 февралендәге 12-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы депутаты статусы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 02 сентябрендәге 16/5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советы депутаты статусы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт өстәргә:

«1.1. Депутат җитди сәбәпләрсез алты ай рәттән шәһәр Советының оештырылган бар утырышларында булмаган очракта, шәһәр Советы карары белән шәһәр Советы депутатының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.»;

1.2. 3 статьяның 3 пунктында, 18 статьяның 1 пунктындагы «б» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 17 статьяның 1 пунктындагы 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне гамәлдәге законнар нигезендә тапшырырга.».

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Интернет мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов